КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 30 ноябрь г.Казань № 1534

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел саен «Уылдык чәчү» операциясен үткәрү турында» 2016 ел, 8 февраль, 80 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел саен «Уылдык чәчү» операциясен үткәрү турында» 2016 ел, 8 февраль, 80 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 12 февраль, 76 нчы, 2019 ел, 22 апрель, 326 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «2014 ел, 18 ноябрь, 453 нче» сүзләрен «2022 ел, 13 октябрь, 695 нче» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына:

Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт экология контролендә (күзәтчелегендә) тотылырга тиешле су объектларына, аларның су саклау зоналары территорияләренә һәм яр буендагы саклау полосаларына карата төбәк дәүләт экология контролен (күзәтчелеген) көчәйтергә;

Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт экология контролендә (күзәтчелегендә) тотылырга тиешле хуҗалык һәм (яки) башка эшчәнлек объектларында калдыклар белән эш итү өлкәсендә төбәк дәүләт экология контролен (күзәтчелеген) көчәйтергә;

су объектларында Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыкларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендәге мәҗбүри таләпләрне үтәү өлешендә төбәк дәүләт геологик контролен (күзәтчелекне) көчәйтергә.»;

5 пунктта:

дүртенче абзацта «3.2 статья буенча (бу максатлар өчен билгеләнмәгән урыннарда сәүдә)» сүзләрен «3.2 ст 1 һәм 2 өл.» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «Балыкчылык буенча федераль агентлыкның Урта Идел территориаль идарәсенең Татарстан Республикасы буенча Су биологик ресурсларына дәүләт контроле, аларны күзәтү һәм саклау бүлегенә» сүзләрен «Балыкчылык буенча федераль агентлыкның Идел-Кама территориаль идарәсенең Татарстан Республикасы буенча су биологик ресурсларына дәүләт контроле, аларны күзәтү һәм саклау бүлегенә» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы абзацта «Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе» сүзләрен «Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгына «Уылдык чәчү» операциясе нәтиҗәләре турында мәгълүматны 2 нче кушымта нигезендә «Уылдык чәчү» операциясен уздыру чорында атна саен Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына җибәрергә, шулай ук Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә, Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсенә, Балыкчылык буенча федераль агентлыкның Идел-Кама территориаль идарәсенең Татарстан Республикасы буенча су биологик ресурсларына дәүләт контроле, аларны күзәтү һәм саклау бүлегенә, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казаларның нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Кече үлчәмле суднолар буенча дәүләт инспекциясенә, «Идел-Кама дәүләт табигый биосфера тыюлыгы» федераль дәүләт бюджет учреждениесе администрациясенә тәкъдим итәргә .

әлеге карарга 1 нче һәм 2 нче кушымталарны (карарга теркәләләр) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 8 февраль, 80 нче
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 30 ноябрь, 1534 нче
карары редакциясендә )

Форма

«__» ________ 20__ ел торышына «Уылдык чәчү» операциясен уздыру барышында Татарстан Республикасының Административ хокук бозулар турында кодексының 3.2 статьясының 1 нче һәм 2 нче өлешләре буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең административ комиссияләре эше турында мәгълүмат

| Т/с | Муниципаль берәмлек исеме | Административ җаваплылыкка тартылган | | | | Салынган штрафлар суммасы, мең сум | Түләтелгән штрафлар суммасы, мең сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | барлыгы | юридик затлар | вазыйфаи затлар | гражданнар | | |
| | | | | | | | |

(Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булган очракта), җитәкче имзасы _______________

_______________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 8 февраль, 80 нче
карарына 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 30 ноябрь, 1534 нче
карары редакциясендә )

Форма

"___" ________ 20___ ел торышына "Уылдык чәчү" операциясенең контроль-күзәтчелек чаралары нәтиҗәләре турында мәгълүмат

| Контроль (күзәтчелек) органы исеме | Контроль-күзәтчелек чаралары үткәрелде | Катнашучы хезмәткәрләр саны | Тәртип бозулар ачыклан-ган | Алынган балык тоту кораллары саны | Административ хокук бозулар турында кузгатылган эшләр саны | Ачыкланган җинаятьләр турында хәбәрләр | Кузгатыл-ган җинаять эшләре саны | Кисәтүләр игълан ителде | Профилак-тик визитлар үткәрелде |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | |

(Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булган очракта), җитәкче имзасы ____________________________________________